## • Яхшы кешеләр турында



# ХӨРМӘТКӘ ЛАЕК УЛ

Быел Нурҗиһан Ибраһимовна Абдрахманованың «Татагропроммехмонтаж» ПМКсында эшли башлавына 20 ел тулды.

Кай ара үткән ул гомер—исең китәр. Нурҗиһан Ибраһимовна үзе белән бер чорда эшли башлаган хезмәттәшләренә күз сала да еш кына көрсенеп тә куя. Әнә монтажчылар Мәүлет Мөхәммәтҗанов, Ринат Мәүлетов, мастер Иван Семенович Казачков, эретеп ябыштыручы Ильяс Минәхмәтов —һәммәсе акрын гына урта яшьтән узып баралар, йөзләрендә җыерчык, чәчләрендә кырау да торган саен мулрак күренә. Ә эшкә энергияләре, омтылышлары— күз генә тимәсен, нәкъ элеккечә, яшьләрчә үк. Әллә ул буын кешеләре шулай микән?

Нурҗиһан Ибраһимовна үзе дә шул чор кешесе бит. Яшь чагында нindидер ПМКда 20 ел эшләрмен дип башына да китермәгән булгандыр әле. Ни дисәң дә, Мәскәү кооперация институтын тәмамлаган кешенең урыны сәүдә, җәмәгать туклануы кебек соңгы вакытта «җылы», модалы саналган тирәдә булырга тиеш иде. Шулай башланып китә дә—ул башта шәһәр универсаль кибетендә экономист булып эшли. Коллектив бик тату була, эшкә дә тиз өйрәнә —әмма оклад кечкенә. Яшь, тормыш башлаган чакта анысы да ай-һай кирәк бит! Колоннаның ул чактагы начальнигы Н. Г. Румянцев аны үзләренә килергә димли һәм менә 1971 елдан бирле ул гел бер эштә диярлек —хезмәт һәм хезмәткә түләү буенча инженер вазифасында. Бу эшчеләрнең хезмәт хакын төгәл контрольдә тота торган иң мөһим, эшле участокларның берсе. Әлбәттә, 20 ел эчендә аның һәр ягын өйрәнеп өлгерде Нурҗиһан Ибраһимовна. Әмма заманалар, хуҗалык итү ысуллары үзгәреп торуны да онытмыйк. Соңгы берничә ел эчендә генә дә «Агропроммехмонтаж» ПМКсы башта яңа оклад белән эшләүгә күчте, аннан хуҗалык исәбен үзләштерде, шуннан соң аның икенче моделе буенча хезмәт куйды. Инде менә январьдан колонна арендада. Һәр чор исәп-хисап работникларыннан белем, төгәллек сорый. Менә яңа ысул—аренда мөнәсәбәте кертелүнең дә үз кыенлыклары, үз мәшәкатьләре булырга тиеш. Хуҗалык исәбенең икенче моделе буенча эшләү коллективка отышлы иде: эшчеләр арасында аңлы дисциплина ныгыды, чыгымнар кимеде, эшләп чыгару арты—шулар хисабына хезмәт хакы да, премияләр дә мул булды. Ә менә арендага күчкәч, базар мөнәсәбәтләре яңа чыгым китереп чыгардылар: быел колонна үз эшчеләренә 87 мең сум компенсация түләргә тиеш. Әлбәттә эш акча кызгануда түгел. Ул шулай ук коллектив акчасы. Әмма аны башка отышлырак максатка кулланганда да була иде ләбаса.

Гомумән, соңгы вакытта һәр җирдәге кебек материал кытлыгы, штат кыскартулар биредә дә бар. Боларның һәммәсе иң элек Нурҗиһан Ибраһимовна аша да үтә. Чөнки ул—3 районга хезмәт күрсәтүче колоннаның профсоюз комитеты рәисе дә. Шуңа да соңгы 2 елда корылган көнкүреш, чишенү бүлмәләре, әле куелып килгән кран-балка, шәһәрдә төзелә торган 33 квартиралы торак йорт—һәммәсенә иң элек ул шатлана. Һәм, әлбәттә, күңелсезлекләр дә аны читләтми.Күптән түгел коллективта 3 кеше штат кыскартуларына эләккән иде, ризалашмыйча югары органнарга кадәр барып җиттеләр. Бу очракта инде Нурҗиһан Ибраһимовна профком члennары сүзен тыңларга булды. Арада бер генә кеше дә әлеге иптәшләр таләбен куәтләмәгәч кенә күңеле тынычлана төште. Коллектив җыелышы да нәкъ шул фикерне алга сөрде. Нишлисең, заманасы шундый: коллектив та, җитәкчелек тә иң элек эшкә сәләтле, намуслы работниклар белән бергә эшләүне хуп күрә. Җитәкчелек дигәннән, колонна администрациясе, профсоюз һәм партия комитетларының уртак тел табып яшәүләрен дә билгеләп үтәргә кирәк. Партком секретаре Н. Ш. Фәтхуллин биредә 7 еллап эшли, кешеләрне белә. Шуңа коллективта эшлекле, стабиль атмосфера тудыруда үзара уртак тел табу да зур роль уйный дип саный тәҗрибәле профсоюз лидеры. Ә Нурҗиһан Ибраһимовна фикере белән коллективта һәрчак санашырга күнгәннәр. Ул күп еллар буе агропромышленность комплексы работниклары профсоюзы райкомы Президиумы члены, 1982 елда трестта «профессиясе буенча иң яхшы» исеменә лаек булды, менә дигән хезмәткәр. Хәер, хикмәт анда гына да түгел, Нурҗиһан Ибраһимовна — коллективның үз кешесе, аның алыштыргысыз өлеше. «Аня апа»—шулай дип эндәшеп, аңа көненә дистәләрчә кеше мөрәҗәгать итә. Ул һәрберсен тыңларга вакыт, һәммәсенә җылы сүз таба, кирәк очракта аналарча киңәшләрен бирә. Үзе ана кеше булганлыктан —алар ире Сәлим Салихович белән өч ул үстерделәр—яшьләргә аерата игътибарлы, аларны аңларга тырыша ул. Бәлки шуңадыр да, малайлары бик ипле, тәртипле булып үстеләр. Олысы Марат Пермьдә хәрби авиация-техник училище тәмамлады, Ерак Әфганстан җиреннән «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән кайтты. Хәзер Уссурийскида офицер булып хезмәт итә. Әфганлы әниләренең һәммәсе кебек үк, Нурҗиһан Ибраһимовна баласы язмышы өчен нинди борчулы еллар кичерүен әле дә оныта алмый. Уртанчысы Марс, кечесе Руслан язмышына төшмәсен иде андый сынаулар!

Нурҗиһан Ибраһимовнаның тагы бер ягына игътибар итми мөмкин түгел: коллектив члennарының һәммәсе турында җылы сүзе, уңай фикере бар аның.

—Ул кешеләргә карата мәрхәмәтле, бик ярдәмчел, кече күңелле. Шуңа без аны бөтенебез хөрмәт итәбез,—ди аның үзе турында колоннаның баш бухгалтеры Р. И. Маняпова.

—Бер дигән хезмәткәр, гаҗәеп гадел, киң холыклы хатын-кыз—бусы «Агропроммехмонтаж» ПМКсы начальнигы С. В. Филиппов бәясе.

Коллектив ветераны Нурҗиһан Ибраһимовна Абдрахманова бу сүзләргә бик лаек.

С. ХӘЙРУЛЛИНА.

# Эш сөючән Рифкать

«Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» дигән сүзләр Рифкатькә дә бик туры килә. Әле мәктәп елларында ук техникага булган мәхәббәте трактор-комбайн тирәсенә илтә, андагы куәтле техника тирәсендә эшләүчеләргә аеруча бер соклану белән карарга мәҗбүр итә иде. Бу кызыксынучан малайны комбайнчы ярдәмчесе итеп билгеләп куйдылар беркөнне. Һәм ул техникага хәвәс икәнлеген раслады да шунда. Ә инде урта мәктәпне тәмамлагач ул үзе трактор рычагы артына утырды. Кайда гына булмасын, эшкә сәләтле кеше бик тиз күренә бит ул, шуңа да Рифкатькә иптәшләре дә, өлкәннәр дә өмет багладылар. Әйбәт эшләде ул, солдат хезмәтенә киткәнче үк шактый тәҗрибә туплады, бирелгән эшне вакытында һәм җиренә җиткереп үтәве белән бик әйбәт яктан күренде.Хәер, Галимҗан абыйның балалары барысы да техника белән сихерләнеп үстеләр. Инде менә хәзер Норлат, Казан, Тольятти шәһәрләрендә яшәүче абыйлары Әсхәт, Фәрит, Сәлихҗан, Сәлимҗан һаман техникага тугрылыклылар—шофер, механизатор булып эшлиләр.

Армиядән кайткач, Рифкать янә тракторга утырды һәм шушы еллар эчендә осталыгын арттырып, ел саен әйбәт уңышларга ирешеп килде.

Үткән ел ул Нәҗип Әхмәтвәлиев җитәкләгән аренда звеносында эшләде. Аларга 1255 гектар җир бирелде, звено 15 кешедән оешты. Алар арасында Рифкать тә бар иде, аны яшь булуына да карамастан, эшкә сәләтле, карусыз булганы өчен звенога алуны хуп күрделәр.

Язгы кыр эшләрен бик әйбәт башкарып чыкты звено, урып-җыюда да тырышлык киметелмәде. Беренче тапкыр бит, сынатмаска кирәк, нәрсәгә сәләтле икәнлегеңне дә күрсәтәсе бар.

Рифкать чәчүдә орлык чыгаруда, кырга ашлама ташуда, аны туфракка кертүдә булды, игеннәрне тукландыруда эшләде. Күп вакыт йөкче эшен дә башкарырга, агрегатларның тик торуына юл куймас өчен аеруча өлгерлек күрсәтергә туры килде. Арендада эшенең авыр да, җаваплы да икәнен үз җилкәсендә татыды ул.

Урып-җыю чорында комбайннардан ашлык ташуда иде. Шулай туры килде, ике уңган механизатор бер звено булып берләштеләр. «Дон-1500» комбайнында Наил Хәсәнҗанов беренче булып барса, аңардан бөртек ташучы Рифкать Гыймалетдинов зур тырышлык күрсәтте. Тәүлеккә 25 рейс ясаган көннәр күп булды.

Ял-йокы белән исәпләшми эшләгән кешенең хезмәт хакы да куанычлы. Аренда звеносының члennарына исәп-хисап ясаганда Рифкатькә 6400 сум акча хисапланган, шуның 5200 сумы кулына бирелгән. Ә бит аренда звеносы оешканга бары тик 6 ай чамасы гына иде әле.

1989 елның нәтиҗәләре нигезендә механизаторлар арасында абыйсы Сәлимҗан колхозда беренче урынны билгән иде, былтыр менә Рифкать моңа лаек булды. Рифкать яшь әле, аның алда күп үрләрне яулыйсы бар. Ләкин шунысын ышанычлы итеп әйтеп була—тырышлыгы, техниканы яхшы белүе, эш сөючән булуы аны зур җиңүләргә илтер. «Эш сөйгәнне ил сөя» диләр бит, нәкъ шуның өчен Рифкатьне дә авыл халкы үз итә.

В. ӘХМӘТҖАНОВ,
«Чишмә» колхозы.

## ЯҢАЛЫКЛАР

Япониянең премьер-министры Тосики Кайфу рәсми визит белән АКШка китте.

x x x

АКШ Гыйрак оппозициясе белән очрашулар үткәреләчәк, дип белдерде дәүләт департаменты.

x x x

Малиның премьер-министры итеп элек финанс һәм сәүдә министры булып эшләгән Сумана Сако билгеләнде. Илдә хәл җайга салынып килә.

x x x

ЧСФРның федераль җыелышы сессиясендә җир турында законны тикшерергә керештеләр. Яңа закон авылда милек тоту мәсьәләсенә ачыклык кертергә тиеш.

# Язмыш кочагында калмасыннар

## Хат эзеннән

Безнең заманда таза, бай йортлар белән янәшә яртылаш җиргә сеңгән, төртсәң аварга торган мондый өйне күзаллавы кыен. Ләкин ни хәл итәсең, Циолковский урамындагы унынчы йортта яшәүче Мария Георгиевна Кузнецова һәм аның 1 группа инвалид кызы Мария нәкъ шундый йортта яшиләр. 1916 елда туган Мария Георгиевна күз яшьләрен сөртә-сөртә өенең түшәменә, идәннәргә, ишеккә күрсәтә.

—Менә карагыз,—ди ул. —Матча терәтеп куйганга гына тора. Ишек тулысынча ябылып бетми. Идәнгә ныграк бассаң, төшеп китәсең. Шулчаклы куркам, кичен түшәм ишелеп безнең өскә төшмәсә ярар иде дип.

Мария Георгиевнаның ире Александр Петрович Кузнецов Бөек Ватан сугышының 1 группа инвалиды. Шундый гаиләне дә оныттырлар икән. Хәтта аның исемен искә алып бәйрәмнәрдә котлау открыткалары да җибәрмиләр. Александр Петрович 1942—1943 елларда 112 нче танк бригадасында, 1943—1944 елларда гвардия истребитель полкында хәрби шофер булып хезмәт итә һәм 1944 елның көзендә каты яралана. Сугыштан соң ул озак яшәми, фронтта алган авыр яралардан вафат була.

—Александр исән булса да моның хәтле азап чикмәс идем,—ди Мария Георгиевна сыкрап. —Болай исә безнең барлыгыбызны да белмиләр. Әнә, Мария ике ай инде мунча кермәгән. Акылга зәгыйфь авыруны гомуми мунчага алып барырга ярамый, ә ванна булмаган бүлмәдә ничек юындырасың ди...

Кузнецовалар суга да интеккән булганнар. Ниһаять, каршыларындагы колонканы көйләгәннәр. Мичләре дә ягарлык хәлдә түгел. Янгынга каршы көрәш инспекциясеннән килсәләр, һичшиксез, мондый мичтән файдалануны тыячаклар. Әйе, фронтовик хатынының хәле җиңел түгел. Җитмәсә, авыру кызы бар. Иң соңгы дәрәҗәгә җитеп яшәүче ана-лы-кызны фатир белән беренче чиратта тәэмин итәргә кирәк иде. Үзләренең әйтүләренә караганда, Кузнецовалар шәһәр Советындагы льготалы чиратта унбишенче булып торалар. Ләкин аларның бер-ике ел көтәрлек тә чамалары юк, чөнки өйләре бүген я иртәгә ишелергә тора. Бирегә берничә мәртәбә килгән махсус комиссия ничек хәл итәр, анысы хәзергә билгесез. Әмма бу кешеләрне язмыш кочагында калдырмыйча, тизрәк ярдәм кулын сузсыннар иде.

Г. РӘХИМОВА.

# Сыйфат—төп күрсәткеч

**Узган ел район колхоз-совхозлары дәүләткә пландагы 83000 урынына 75360 центнер терлек саттылар.** Күрганегезчә, бу план бары 90,8 процентка гына үтәлде дигән сүз, 33 хуҗалыкның 10 сы гына әлеге төр планны уңышлы гамәлгә ашырдылар. Алар арасында «Россия», Ульянов исемендәге, «Правда», Мичурин исемендәге, «Большевик», «Таң» колхозлары бар.

Узган ел бер мөгезле эре терлекнең тапшыру авырлыгы 417 килограмм, ягъни алдагы елдан 7 килограммга кимрәк булды. Бу район буенча 711 центнер югалту дигән сүз. Аерым хуҗалыкларда торышны анализласак, бу хәл тагы да мөшкелрәк булуын күрергә мөмкин. Сәбәп нәрсәдә? Белгечләр аны ирексездән суелган терлек дип аңлатырга тырышалар, әмма бу алай түгел. Бөтен сәбәп шунда: халыктан кабул ителгән түбән көрлелектәге маллар симертелмичә, турыдан-туры ит комбинатына озатыла. Нәтиҗәдә, хуҗалыклар гаҗәеп зур югалтулар кичерәләр. Мәсәлән, Синдряков исемендәге колхоз 259 центнер арык мал тапшырды, нәтиҗәдә 28490 сум югалту күрде. «Восход», «Игенче», «Алга», XXI партсъезд исемендәге, «Комбайн», «Таң» колхозлары һәм «Мамык» совхозы да ябык маллар сатудан зур зыян кичерәләр. Муса Җәлил исемендәге колхоз, «Путь к коммунизму», «Восход», «Алга», «Татарстан» колхозларыннан дуңгызларның 35—16 проценты стандарт булмаган авырлыкта тапшырылды. Шул ук сәбәптән «Төрнәс» совхозы 17712, «Мамык» совхозы 22282, «Рассвет» совхозы 32882 сум зыянга эшләделәр. Андый югалту район буенча 315290 сумга җитте.

Сарыкчылыкта да шундый ук хәл күзәтелде. Ит комбинатына тапшырылган 4066 баш сарыкның 54 проценты урта көрлектән югары, 11 проценты урта, 23 проценты урта көрлектән түбән һәм 13 проценты арык терлекләр. Моңарчы булмаганча, «Родина» колхозы сарыкларның 38 процентын ябык көрлектә тапшырды. «Алга», «Комбайн», «Кондырча» колхозларында 18, 22, 20 процент сарыклар шулай ук арык көрлектә иде.

Кызганычка каршы, быел да бу җәһәттән әлләни алга китеш юк. 3 айлык нәтиҗәләрдән күренгәнчә, хуҗалык җитәкчеләре, белгечләр узган ел сабакларыннан тиешле нәтиҗә ясамаганнар. Беренче кварталда пландагы 28000 центнер урынына 21711 центнер терлек сатылган. Планны уңышлы үтәгән «Россия», Мичурин исемендәге, «Таң», «Москва», Кузнецов исемендәге хуҗалыклар белән янәшә аны 27 процентка гына үтәгән «Сөлчә» совхозы да барын онытмыйк. «Чирмешән», «Восход», «Знамя Октября», «Комбайн», «Үрнәк», «Чишмә» колхозларында да план үтәлеше 41—69 процент кына тәшкил итә. План үтәлмәсә үтәлми, аның каравы хуҗалык эчендәге сарыф итүләр артканнан арта бара. Шул ук «Сөлчә» совхозы дәүләткә 192 центнер ит сатса, хуҗалык эчендә 44 центнер, ягъни узган елдагыдан 27 центнерга күбрәк продукция тотты. Синдряков исемендәге колхоз бу максатларда итне 23, Хафизов исемендәге 32, «Төрнәс» совхозы 50 центнерга артыграк сарыф иттеләр. Бу исемлекне тагы да дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Әмма җитәкчеләр, белгечләр бер нәрсәне онытала: әлеге максатта планның 4,5 проценты кадәрен генә кулланырга мөмкин. Шул ук вакытта хуҗалыкларда маллар суюның тәртибе дә юк. Бракка чыгару акты үзвакытында төзелми, төзелгән очракта да ул складка тапшырылганнан соң гына фиктив документ әвәләп куялар. Мәсәлән, «Правда» колхозы 3 айда 21 баш мөгезле эре терлек суйды, бер баш малның уртача авырлыгы 152 килограмм (!) тәшкил итте. Хафизов исемендәге колхозда, гомумән, һәр терлек 112 килограмм белән генә исәпләнде. Бу чорда дәүләткә сатылган малларның авырлыгы 413 килограммнан артмады. Игътибар итегез: бу узган елның шул чоры белән чагыштырганда 21 килограммга (!) кимрәк. Шуның нәтиҗәсендә 530 центнер арык сыер ите, 481 центнер стандарт булмаган дуңгыз ите тапшырылды. Әгәр 1 тонна уртачадан югары көрлектәге һәм арык мал ите арасындагы аерма 6960 сум, ә уртача көрлектәгесендә 5666 сум икәнлеген истә тотсак, югалтуларның нинди түгәрәк саннар белән билгеләнүен күз алдына китерүе авыр түгел. Мөгезле эре терлекләрдән 368880 сум, дуңгызлардан 120864 сум.

Шулай итеп, сыйфат күрсәткече җитмәүдән генә дә кассаларны 489744 сум акча читләп үтте.

Хуҗалык елы дәвам итә. Яңа базар мөнәсәбәтләре бездән һәр нәрсәне уйлап, исәпләп эш итүне сорый. Бу җитештерелгән, сатылган продукциянең сыйфатына да турыдан-туры кагыла. Чөнки бүген сыйфат—акча эшләүдә, табыш алуда шулай ук төп күрсәткеч.

**А. БЕЛЯКОВА,**
авыл хуҗалыгы продукциясе сатып алу һәм сыйфат буенча дәүләт инспекторы.

# Сөендерде дә, уйландырды да

31 март көнне Аксубай районының Шәрбән авылында татарча көрәш буенча Социалистик Хезмәт Герое Ш. С. Хафизов исемендәге кубок өчен ярышлар булды. Шәрбән—Шәриф Сәгыйровичның туган авылы үз геройлары истәлегенә зур ихтирам белән карый икән. Беренче тапкыр гына үткәрелсә дә, ярыш бик оешкан төстә үтте. Анда район авыллары белән бергә безнең Хафизов исемендәге колхозга да чакыру килгән иде. Хуҗалык данын якларга Фәнил Гайнуллин, Хәлим Шәрипов, Фаил Хаҗиморатов һәм Ислам Гайсин бардылар. Егетләр әйтергә кирәк, бик уңышлы чыгыш ясадылар. 8 команда арасында 75 килограммга кадәрге авырлыкта безнең Хәлим Шәрипов 1 нче урынны яулады. Хәлимнең үз-үзен чын көрәшчеләрчә нык тотуы, техник әзерлеге бөтенесендә урынлы соклану уятты. Бер генә дә җиңелүгә дучар ителмичә, ул хаклы дәвештә 1 нче урынны алды.

Авыр үлчәмле категориядә Ф. Гайнуллин һәм Ф. Хаҗиморатов шулай ук призлы II—III урыннарны яуладылар.

Шулай итеп, безнең егетләр ярышта матур гына нәтиҗәләргә ирешеп кайттылар. Әмма дөресен әйтергә кирәк, ярыш бер яктан шатландырса, икенче яктан күңелне дә тырнап алды. Ни өчен шәрбәнлеләр үз якташлары ядкәренә шундый сак караш булдыра алганнар да, без, үз җиребездә Шәриф Сәгыйрович герой исеме алган, гомере буе эшләгән төбәк шундый нәрсәне оештыра алмыйбыз? Аңа гына чыгымнар таба алмыйбызмы? Әле соң түгел, бу хакта һичшиксез уйланырга кирәк.

**В. ШӘЙХЕТДИНОВ,**
Кормыш авыл Советы рәисе.



**ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: «40 лет Победы» колхозы механизаторы Кәбир Абдуллович Вәлиев.**

**Кәбир Абдулловичның корыч айгырлар иярләвенә 33 еллап инде. Соңгы ике елда ул Таһир Хәлимов җитәкчелегендәге аренда звеносы составында эшли. Бөртекле культуралар һәм шикәр чөгендере игү белән шөгыльләнүче бу звенода ул—иң өлкән, иң тәҗрибәле механизатор. Шуңа да аның ДТ-75 тракторына күбрәк туңга сөрү, чәчү кебек җаваплы эшләр тапшырыла. Сабыр холыклы, карусыз, ярдәмчел. Кәбир Абдуллович яшьләргә киңәш-табыш итүдә дә һәрчак таяныч.**

**Хәзер колхоз механизаторлары авыл хуҗалыгы машиналарын комплектлау, агрегатлау белән мәшгульләр. Механизатор К. Ә. Вәлиев та быелгы җаваплы чәчү чорын тулы әзерлектә, хезмәт күтәренкелегендә каршылау өчен тырыша.**

## *Кыскача*

1991 елның январена илдә 60 миллион пенсионер исәпләнде. Тагын бер миллион кеше туйдыручысын югалтканга күрә пенсияләр һәм пособиеләр ала. Әлегә халыкның күпме өлеше хәерчелек дәрәҗәсендә яшәү турында төгәл мәгълүмтлар юк. Бу сан Россия өчен генә мәгълүм—якынча 4,5 миллион кеше 70 сум һәм аннан кимрәк пенсия ала.

x x x

Бер ел эчендә безнең кибет киштәләреннән 23 исемдәге икмәк ризыклары, 21 исемдәге ит, 20 исемдәге балык, 17 исемдәге сөт ризыклары, 14 исемдәге кондитер әйбере, 15 исемдәге яшелчә-җимеш, 26 төр яшелчә һәм җимеш консервлары юкка чыкты.

x x x

Ватаныбыз амбарлары, узган елда мул уңыш үстерелүгә карамастан, шулай ук такыр. Дәүләт статистика комитеты мәгълүматларына караганда, базарларда ит һәм кош ите, казылык, ит консервлары, май, сыр һәм башка төр продуктлар узган елдагыдан азрак. Йомырка узган елгы запастан 10 тапкырга ким! Балык узган елдагының яртысы кадәрле. Шикәр җитәрлек. Аның запаслары 2533,6 мең тоннага җитте, узган ел исә 1614 мең тонна гына иде.

**(«Аргументы и факты»).**

## 02 хәбәр итә

Быелның I кварталында районда оператив хәл катлаулы булып калды. 80 җинаять эшләнде. Алар арасында үтерү, көчләү, хулиганлык эшләү, урлау кебек авыр җинаятьләр дә бар. Гражданнарның шәхси милкен урлауның 14, дәүләт әйберләрен урлауларның 12 факты ачылды. Болар предприятие, колхоз һәм совхоз җитәкчеләренең җавапсызлык күрсәтүләре нәтиҗәсе булып тора.

1991 елның 27 мартында Кузнецов исемендәге колхоз рәисе кабинеты тәрәзәсенең рамын алып, бухгалтерия һәм касса бүлмәсенең ишеген, йозагын ватып билгесез җинаятьчеләр тимер ящиктан 8,948 сумда, 25, 10, 5, 3, 1 сумлык кәгазь акчалар һәм 5—6 сум тирәсендә вак акчалар, 78 сумлык микрокалькулятор, чәшкә коерыгыннан эшләнгән 58 размерлы «Боярка» хатын-кызлар шапкасы (бәясе 130 сум), «молния» замоклы 36 размерлы, 23 сумлык итек-бурка, 10 сум 30 тиенлек 3 шешә «Пшеничная» аракысы, 3 пачка «Реус» сигареты урладылар.

Әлеге җинаять турында нинди дә булса мәгълүматлар белүче гражданнардан Октябрь эчке эшләр бүлегенә 2—19—02, 2—11—25 телефоны аша хәбәр итүегезне сорыйбыз. Җинаятьне ачуда булышучы хәбәрләр белдергән гражданнарга бүләкләр биреләчәк.

x x x

Быелгы елның 3 аенда җәмәгать урыннарында һәм көнкүрештә 300 дән артык вак хулиганлык эшләнде. Җәмәгать урыннарына исерек хәлдә килгән 329 кеше өстеннән милиция хезмәткәрләре протоколлар төзеде. Шикәр заводынан 15 кеше вак хулиганлык, 5 се исереклек, Норлат-Октябрь элеваторыннан 11—9, МСОдан 11—12, Хафизов исемендәге, «Родина» колхозларыннан, «Төрнәс», «Рассвет» совхозларыннан 11—12 кеше тоткарланды.

Ә менә ПМК, 53 нче СМУ, Муса Җәлил исемендәге, «Таң» колхозлары коллективларында быел бер генә тапкыр да җәмәгать тәртибен бозу фактлары булмады.

x x x

Вак хулиганлык кылучылар белән актив көрәш алып барыла. Кыска гына вакыт эчендә дәүләт байлыгын урлаган 60 тан артык кеше тотылды. Бу җөмләдән шикәр заводы, сөт, ит комбинатлары һәм икмәк заводы коллективлары аеруча танылдылар. Шикәр заводыннан эшче Г. Ф. Ерепов 15 килограмм, Х. А. Кәримова 3 килограмм, Е. И. Гусев 10 килограмм шикәр комы белән тотылдылар, ит комбинатыннан З. С. Абрамова, М. И. Шәйхетдинов, М. Х. Харисова һәм башкалар ит продуктлары, сөтмай комбинатыннан В. Г. Захарова, Г. Л. Ишмуллина һәм башкалар каймак, сыр, эремчек белән тотылдылар.

x x x

Самоган куу һәм спиртлы эчемлекләр сатучылар белән көрәш тә кимеми. Өч айда самогон куган 48 факт ачыкланды, 400 литрдан артык сыра, 15 литрдан артык самогон алынды. 18 кеше административ җаваплылыкка тартылды, ягъни 100 сумнан 300 сумга кадәр штрафка тартылды. Мондый фактлар «Россия», «Знамя Октября», «Правда», «Родина» һәм башка колхозларда ачыкланды. Норлат шәһәрендә яшәүче Е. К. Михеева, «Төрнәс» совхозыннан пенсионерка И. С. Ермуллина, Кара Күл авылыннан Б. И. Шакиров самогон кууда гаепләнеп җинаять җаваплылыгына тартылдылар.

**Р. ТӘМАЕВ,**
район эчке эшләр бүлегенең профилактик служба начальнигы, милиция капитаны.

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ

**СИШӘМБЕ**
**9 АПРЕЛЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.00 «Бергәләп өйрәник».
17.30 «Бәла». Нәфис фильм.
19.00 «Татарстан».
19.30 Г. Тукай премиясенә кандидатлар. Шагыйрь Роберт Миңнуллин.
20.10 «Әлли-бәлли-бәү».
20.20 «Нәтиҗә». «Яшелчәчеләрнең язгы мәшәкатьләре».
20.50 «Балтачларга барган идек...» Үзешчән сәнгатьтә катнашучылар чыгышы.
21.40 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 «Иртә».
9.00 «Актуаль репортаж».
9.20 Мультфильм.
9.30 Документаль фильм.
9.50 «Гафу ит безне, үги анабыз Россия». Нәфис фильм. 1 нче серия.
11.00 «Балалар сәгате». (немец теле дәресе белән).
12.00 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
12.15 «Җыр турында хатирәләр».
15.00 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
15.15 «Омтылыш». Нәфис фильм.
16.30 «Музыка хәзинәләре».
17.00 «Чемпионнар белән бергә».
17.30 «Рок-дәрес». Яшүсмерләр өчен программа.
18.30 «Меридиан».
18.45 «Сәяси диалоглар».
19.30 Мультфильм.
19.35 Документаль фильм премьерасы.
20.05 «Ялгызак». Нәфис фильм. 2 нче серия.
21.00 «Вакыт».
21.45 «ВиД» тәкъдим итә: «Могҗизалар кыры».
22.30 «Ачыктан-ачык сөйләшү».
23.30 Скрипкачы Ю. Рахлин (Австрия).
00.10 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
00.30 «Миргород һәм анда яшәүчеләр». Нәфис фильм. 1 нче серия.
01.40 Эстрада программасы.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Фәнни-популяр фильм.
8.35, 9.35 География. 8 кл.
9.05 Француз теле. 1 нче уку елы.
10.05 Француз теле. 2 нче уку елы.
10.35, 11.40 Табигать белеме. 2 класс.
10.55 «Компьютер белән диалог».
12.00 Мультфильм.
12.15 «Троян чаптары». Нәфис фильм. 1 нче серия.
13.20 «Роберт Газизов җырлары»
13.45 Ритмлы гимнастика.
14.15 «Музыкаль абонемент».

**ЧӘРШӘМБЕ**
**10 АПРЕЛЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.05 «Музыка дөньясына сәяхәт». Композитор Ф. Яруллин.
17.25 «Сез кемнәрнеке, картлар?». Нәфис фильм.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Нәтиҗә». Игенчеләрнең язгы мәшәкатьләре.
20.00 «Әлли-бәлли-бәү».
20.10 «Кешеләрне җылытыгыз». Казанның җылылык челтәре предприятиеләре эше турында.
20.30 «Тәрәзәләрдә нурлар». Азнакай районының Вахитов исемендәге колхоз эшчәннәренә багышланган музыкаль-информацион тапшыру.
21.30 Реклама.
21.40 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 «Иртә».
9.00 «Эшлекле курьер».
9.20 Молдованың музыкаль фольклоры концерты.
10.55 «Гафу ит безне, үги анабыз Россия». Нәфис фильм. 2 нче серия.
11.00 «Рок дәресе».
12.00 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
12.15 Документаль фильм.
15.00 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
15.15 «Айлы төндәге атлар». Нәфис фильм.
16.20 Концерт.
16.55 Ю. А. Гагаринның космоска очуына 30 ел тулуга багышланган тантаналы утырыш.
18.15 «Биредә Ленин эшләде һәм яшәде». Документаль фильм.
18.25 «Мәдәният һәм базар».
18.55 Футбол. Европа чемпионнары кубогы. Ярымфинал. «Спартак» (Мәскәү)—«Марсель (Франция).
21.00 «Вакыт».
21.45 «Ялгызак». Нәфис фильм. 3 нче серия.
22.35 Ю. А. Гагаринның космоска очуына 30 ел тулуга багышланган концерт. Тәнәфестә—«Телевизион яңалыклар хезмәте».
00.55 «Миргород һәм анда яшәүчеләр». Нәфис фильм. 2 нче серия.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Фәнни-популяр фильм.
8.35, 9.35 Табигать белеме. 3 класс.
9.05 Немец теле. 1 нче уку елы.
10.05 Немец теле. 2 нче уку елы.
10.35, 11.35 Гомуми биология. 10 класс.
11.05 «Бурда моден» тәкъдим итә...».
12.05 «Көнчыгыш Себер». Киножурнал.
12.15 «Троян чаптары». Нәфис фильм. 2 нче серия.
13.10 «Испан сәгате». М. Равель музыкасына фильм-опера.
14.00 Мультфильм.
14.15 «Иркуйем кая китте». Телефильм.
21.45 «Мин сезгә мәхәббәт турында сөйлим».
22.50 «Кайту». Документаль фильм.

**ПӘНҖЕШӘМБЕ**
**11 АПРЕЛЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.05 «Ералаш». Киножурнал.
17.15 «Сезнең өегезгә газ килде». Киноплакат.
17.30 Нәфис фильм. «Борылгачта блондинка булыр».
19.00 «Әлли-бәлли-бәү».
19.40 «Шигърият».Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов.
20.15 «Депутат каналы».
21.00 «Җыр чишмәләре». Шакир Мәҗитов иҗаты турында.
21.30 Реклама.
21.40 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 «Иртә».
9.00 «МВД белешмәләре буенча».
9.20 Футбол. Европа чемпионнары кубогы. Ярымфинал. «Спартак». (Мәскәү).—«Марсель» (Франция).
11.00 «Балалар сәгате» (инглиз теле дәресе белән).
12.00 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
12.15 Концерт.
15.00 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
15.15 «Мәхәббәт турында җыр». Нәфис фильм.
16.35 «Мавыгучылар дөньясы».
16.50 «Әгәр сезгә...»
17.35 «... уналтыга кадәр һәм өлкәнрәк».
18.30 «Меридиан».
18.45 Документаль фильм премьерасы.
18.55 «Кеше. Җир. Галәм».
19.55 «Ялта-91».
20.05 «Ялгызак». Нәфис фильм. 4 нче серия.
21.00 «Вакыт».
21.45 «МВД белешмәләре буенча».
22.00 «Җырлыйк, дуслар».
00.00 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
00.20 «Каршылык күрсәтү билгесе». Нәфис фильм.
01.40 Фильм-концерт.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Фәнни-популяр фильм.
8.35, 9.35 Гомуми биология. 11 класс.
9.05 Испан теле. 1 нче уку елы.
10.05 Испан теле. 2 нче уку елы.
10.35, 11.35 Биология. 8 кл.
11.05 «Безнең бакча».
12.05 Документаль фильм премьерасы.
12.45 Саратовта хор музыкасы бәйрәме.
13.15 Ритмлы гимнастика.
13.45 «Россиянең документаль экраны».
21.45 «Җилләтергә куйган таяк». 1, 2 нче серияләр.

**ҖОМГА**
**12 АПРЕЛЬ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.35 Мультфильм.
17.45 «Әти, әни һәм мин —музыкаль гаилә». I Республика смотрының йомгаклау концерты (язмада).
19.00 «Татарстан».
19.30 «Җомга көн кич белән». Альманах.
20.10 «Әлли-бәлли-бәү».
20.20 Г. Тукай премиясенә кандидатлар. Композитор А. Монасыйпов.
21.25 «Аяк киемең тар булса...». «Спартак» производство берләшмәсе яшьләре турында.
21.40 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 «Иртә».
9.00 Мультфильм.
9.05 «Җырлыйк, дуслар».
11.05 «... уналтыга кадәр һәм өлкәнрәк».
12.00 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
12.15 Документаль фильм
13.05 «Калинка» ансамбле чыгышы (Калуга шәһәре).
15.00 «Телевизион яңалыклар хезмәте».
15.15 «Беренче көн, соңгы көн». Нәфис фильм.
16.25 Мультфильмнар.
17.05 Фәнни-популяр фильм.
17.25 Музыкаль программа.
17.55 Әкиятләр һәм маҗаралар дөньясында. «Нәни Мук маҗаралары». Нәфис фильм.
19.15 Ю. А. Гагаринның космоска очуына 30 ел тулуга багышланган халыкара телефестиваль.
21.00 «Вакыт».
21.45 Ю. А. Гагаринның космоска очуына 30 ел тулуга багышланган халыкара телефестивальнең дәвамы.
23.00 «ВиД» программасы. Тәнәфестә— «Телевизион яңалыклар хезмәте».
01.20 «Шерлок Холмс һәм доктор Ватсон маҗаралары». Нәфис фильм. 1 нче серия.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Фәнни-популяр фильм.
8.35, 9.35 Әдәбият. 5 кл.
9.05 Инглиз теле. 1 нче уку елы.
10.05 Инглиз теле. 2 нче уку елы.
10.35, 11.35 Әдәбият. 6 кл.
11.05 «Сәламәтлек».
12.05 «Җилләтергә куйган таяк». Нәфис фильм. 1, 2 серияләр.
14.25 Документаль фильм.
17.00 «Номыд» (Сыктывкар).
21.45 «Спорт һәркем өчен».
22.00 «Төнге визит». Нәфис фильм. 1, 2 нче серияләр.




Чулпан авылында яшәүче кадерле әтиебез һәм тормыш иптәшем Кәшаф Кыяметдин улы Гайнетдиновка 60 яшь тулу уңае белән кайнар котлыйбыз. Аңа корычтай нык сәламәтлек, озын гомер, шатлыклы, тыныч тормыш телибез.

**ТОРМЫШ ИПТӘШЕ, БАЛАЛАРЫ, ОНЫКЛАРЫ.**

* * *

Кадерле әтиебез һәм тормыш иптәшем Гариф Сафиулла улы Гомәровны 50 яшь тулу көне белән чын күңелебездән котлыйбыз. Әтиебезгә исәнлек-саулык, озын гомер, шомырт чәчәгедәй ак бәхетләр теләп калабыз.

**ТОРМЫШ ИПТӘШЕ, КЫЗЫ, КИЯВЕ, УЛЛАРЫ, КИЛЕНЕ, ОНЫКЛАРЫ.**

## *Үткен сүзләр*

**КӨЧЛӘР ТИГЕЗ БУЛМАСА**

Концерттан соң берәү, композитор янына килеп:

—Күпме утырдым бу концертта, ләкин, әйтергә кирәк, бернәрсә дә аңламадым,—ди.

—Концертка бит билетны теләсә кемгә саталар, —ди композитор.

**ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР**

—Сезнең авыл моннан ничә чакрым?

—Элек сигез иде. Ә хәзер багана утырттылар да ун дип язып куйдылар. Йөре инде шул артык ике чакрымны таптап...

**КАЙСЫ ЕЛДА**

Җыелыш азагында карар проекты укыла:

«Фермада эшләүчеләр өчен ял бүлмәсен унбишенче майга кадәр салып бетерергә».

Шул чакны берәү килә дә әйтә:

—Кайсы елның мае икәнен күрсәтмичә дөрес эшлисез.

**АТА ҺӘМ БАЛА**

Малай әтисенә сорау бирә:

—Сөйләшергә өйрәнгәч, кеше тагын нишләргә тиеш?

—Дәшми тора белергә тиеш.

**КОСТЮМ ТЕККӘНДӘ**

—Шундый яхшы, затлы материалдан бик начар костюм теккәнсез!

—Начар материалдан да тегеп карадык, барыбер шундый булды.




**Район Советы башкарма комитетының хуҗалыкара производство предприятиесе карамагындагы шәһәр мунчасына билет бәясе 95 тиенгә кадәр күтәрелә.**

x x x

**«Норлатнефть» НГДУсы халыктан килешү бәясе белән бәрәңге, суган, кызыл чөгендер, кишер, кабак кабул итә. Түләү урында башкарыла.**

x x x

**ТССРда 1991 елның 2 апреленнән пассажирларны йөртүче автобусларда билет бәясе арту сәбәпле, Норлатта да шәһәр автобусларына билет бәясе 15 тиен торачак. Бер якка бару өчен 5 тиенлек 3 абонемент талонын компостерда бастырырга кирәк. Шәһәрара һәм авыл маршрутларында йөрүче автобусларда билет бәясе ике тапкыр арта.**


Мөхәррир урынбасары **Р. З. АЙЗАТУЛЛИН.**

**Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы һәм КПССның район партия оешмасы.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

Газетаны Нурзия **ФӘСХЕТДИНОВА** җыйды. Асия **МОРАТХАНОВА** верстка ясады. Клара **БОБКОВА** басты. Корректор— **ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВА.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак.** Заказ 41. **Тираж 3.350.**